СОВЕТ
НОВОБУРУНДУКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Улица Вокзальная, дом 31,
П.ж.-д.ст.Бурундуки, Дрожжановский район 422490

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА БОРЫНДЫК
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Вокзал урамы, 31 нче йорт,
Борындык тимер юл ст. поселогы,
Чүпрәле районы
422490

Тел.: (84375) 3-17-45, 3-17-03, факс: (84375) 3-17-45, e-mail: Nbur.Drz@tatar.ru,
www. Nbur -drogganoe.tatarstan.ru

# КАРАР

2024 нче елның 12 ноябрь № 54/2

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 25 декабрендәге 628-ФЗ номерлы Федераль законына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Уставының 32 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге Советының 03.06.2022 № 23/1 (16.12.2022 №31/2, 27.02.2023 №34/1, 31.07.2023 №39/1, 15.11.2023 №43/4, 23.05.2024 №49/2 редакциясендә) карары белән расланган, Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлегендә бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

5 статьяның 7 пунктындагы 7 абзацында «тапшыра» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләү көненнән дә соңга калмыйча»сүзләрен өстәргә.

2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр 11 статьяның 1 пунктының гамәлдә булуын туктатып торырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Борындык авыл җирлеге уставында билгеләнгән тәртип нигезендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм махсус мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Яңа Борындык авыл җирлеге башлыгы: В.Г. Ранцев